ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

8 май, 2026 ел 7/7

Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 21 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә (Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/12, 2018 елның 27 апрелендәге 24/9, 2022 елның 23 июнендәге 15/11, 2024 елның 7 августындагы 35/15 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«7. Башкарма комитет:

1) даими йөртү өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) даими йөртүне планлаштыру документын әзерләү тәртибен билгели;

3) даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча даими йөртүнең муниципаль заказчысы функциясен башкара, муниципаль контракт төзи, котракт шартлары үтәлешен контрольдә тота һәм даими йөртү маршруты карталарын бирә;

4) даими йөртү муниципаль маршрутында даими йөртү хокукына ачык конкурс оештыручы функцияләрен башкара, конкурста катнашуга гаризалар критерийларын бәяләү өчен шкала билгели, конкурс документациясен раслый, даими йөртү муниципаль маршруты буенча даими йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими йөртү маршрут карталарын бирә;

4.1) даими йөртү муниципаль маршрутында даими йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими йөртү маршрут карталары дубликатын бирү тәртибен билгели, даими йөртү муниципаль маршрутында даими йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими йөртү маршрут карталары дубликатын бирә;

5) даими йөртү муниципаль маршруты буенча даими йөртү хокукына ачык конкурс уздыру турында хәбәрне һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгели;

6) даими йөртү муниципаль маршруты буенча даими йөртү хокукына ачык конкурста катнашуга гариза формасын һәм әлеге гаризаның эчтәлегенә (шул исәптән ачык конкурста катнашучы тәкъдименең тасвирламасына) таләпләрне билгели;

7) даими йөртү муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, аңа даими йөртү муниципаль маршрутларында даими йөртү төрен үзгәртү турында мәгълүмат кертү тәртибен раслый, даими йөртү муниципаль маршрутлары реестрын алып бара;

8) даими йөртү муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүдән яки үзгәртүдән баш тарту өчен әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару өчен нигезләрне) раслый, даими йөртү муниципаль маршрутларын билгели, үзгәртә һәм гамәлдән чыгара;

9) муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан, даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителә торган тукталыш пунктлары исемлеген билгели;

10) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына даими йөртү муниципаль маршрутлары хакында муниципаль берәмлек территориясендә тукталыш пунктлары билгеләү тәкъдимнәре җибәрә;

11) зарур булганда даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча җайга салынмый торган тарифлар буенча йөртүгә таләпләр билгели;

12) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль кысаларында даими йөртүне оештыру өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыра;

13) даими йөртүне оештыру өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

2) 8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«8. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә даими йөртүнең муниципаль маршрутлары Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән билгеләнә, үзгәртелә, гамәлдән чыгарыла.»;

3) 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Даими йөртү муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гади ширкәтнең муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару турындагы шартнамәсендә катнашучыларның гаризаларын карау тәртибе, шулай ук муниципаль маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр, муниципаль маршрутларны гамәлдән чыгару өчен нигезләр). Даими йөртү муниципаль маршрутларына карата Башкарма комитетның түбәндәге хокукый акты нигезендә билгеләнә:

1) юл шартларының хәрәкәт иминлеге таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү акты;

2) муниципаль норматив хокукый актта билгеләнгән тәртип нигезендә төзелгән маршрутта пассажирлар агымын тикшерү акты.»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 9.1., 9.2. пунктлар өстәргә:

«9.1. Элек билгеләнгән даими йөртү муниципаль маршруты, даими йөртү муниципальара маршруты белән ике һәм аннан күбрәк гомуми тукталыш пункты булган даими йөртү муниципаль маршрутын билгеләү яисә үзгәртү вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм Башкарма комитет арасында килештерү нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән килештерү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

9.2. Даими йөртү муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы карарлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органының рәсми сайтында яисә күрсәтелгән карарларны кабул иткән шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.»;

5) 10 пунктта:

- «гамәлгә ашыру турында таныклык бирелде» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы бирелде» сүзләренә алыштырырга;

- «таныклык» сүзен «хокук» сүзенә алыштырырга;

- «йөз сиксән» сүзен «180» санына алыштырырга»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 10.1. пункт өстәргә:

«10.1. Даими йөртү муниципаль маршрутын үзгәртү турында Башкарма комитет карар кабул иткән көннән алып 60 көн эчендә муниципаль маршрутлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр, гади ширкәт шартнамәсендә вәкаләтле катнашучы мондый таныклыкларның һәм карталарның гамәлдә булуын киләсе срокка озайту турында гаризалар белән Башкарма комитетка кабул ителгән карар нигезендә мөрәҗәгать итәргә тиеш.»;

7) 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. Даими йөртү муниципаль маршрутлары Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 1 - 10 пунктларында каралган муниципаль маршрутлар турындагы мәгълүматлар даими йөртү реестрларына кертелгән көннән, Федераль законның 26 статьясы 1 өлешенең 3 - 10, 12 пунктларында каралган мәгълүматлар әлеге реестрларда үзгәртелгән көннән билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала.»;

8) 14 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«14. Даими йөртү муниципаль маршрутлары, даими йөртү муниципаль маршрутлары реестрларына муниципаль маршрутларны гамәлдән чыгару турында мәгълүмат кертелгән көннән алып, гамәлдән чыгарылган дип санала.»;

9) 18 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«18. Даими йөртү маршрутлары реестрына Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешендә каралган мәгълүматлар кертелергә тиеш. Даими йөртү муниципаль маршрутлары реестрына кертелгән мәгълүматлар (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны турындагы мәгълүматтан тыш) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органының рәсми сайтында яисә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматларны урнаштыру форматы текст файлларын һәм электрон таблицаларны төзү, карау һәм төзәтү өчен билгеләнгән электрон исәпләү машиналары программаларын һәм белешмәләр базаларын кулланып, аларны сайлап алу һәм сортларга аеру мөмкинлеген күздә тотарга тиеш.»;

10) 23 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«23. Җайга салына торган тарифлар буенча пассажирларны даими йөртү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә Башкарма комитеты (алга таба - муниципаль заказчы) тарафыннан дәүләт яисә муниципаль контракт төзү;

2) Концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары нигезендә пассажирларны һәм багажны даими рәвештә йөртү һәм аларның хәрәкәтен технологик яктан тәэмин итә торган объектларны эксплуатацияләү өчен шәһәр җир өсте электр транспортының (трамвайлар, троллейбуслар), тышкы чыганактан (электробуслардан) корыла торган батареядан электр энергиясе белән хәрәкәткә китерелә торган автобуслардан файдалануны күздә тоткан концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзүләр - бу даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документында яисә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планында каралган очракта.»;

11) 28 пунктта «даими йөртүнең тиешле маршруты буенча йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «маршрутның тиешле төре реестрына язма кертү» сүзләренә алыштырырга»;

12) 42 пунктта түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктча өстәргә:

«11) даими йөртү маршрутын гамәлдән чыгару турындагы карарның үз көченә керүе.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев